РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» 04 2026 ел №421

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турында 19.10.2021 ел, № 850 нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

"Гражданнар оборонасы турында" 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ санлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында"гы 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 санлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 санлы Указы, «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен төзү һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 июлендәге 496 санлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын билгеләнеше буенча куллануга даими әзерлектә тоту, хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халыкны хәвеф-хәтәрләрдән яклауны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 19.12.2021 № 850 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турындагы нигезләмәгә (алга таба — нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - хәвеф-хәтәрләр килеп чыгу нәтиҗәсендә зыян күргән халыкның тормышын беренче чиратта тәэмин итү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05